| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2024 п.г.т. Алексеевское № 479

**2025-2027 елларга Алексеевск муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасы турында**

Алексеевск муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында

**карар бирәм:**

1. 2025 - 2027 елларга Алексеевск муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Алексеевск районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгәнчә программаны Алексеевск муниципаль районы бюджетында каралган акчалар исәбеннән финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_12.11.2024 ел._ № _479_
карарына кушымта

**2025 - 2027 елларга**
**Алексеевск муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасы**

**1 бүлек. 2025 - 2027 елларга Алексеевск муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2025 - 2027 елларга Алексеевск муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту программасы (алга таба-Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы законы |
| Программаны төп эшләүчеләр-инфраструктура үсеше бүлеге | Заказчы<br>Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаны үтәүчеләр | Алексеевск муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| Программаның максатлары | Район сешмаларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту |
| Программаның бурычлары | - производствода травматизм дәрәҗәсен киметү, беренче чиратта авыр һәм үлем белән тәмамланган; |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | - хезмәткәрләрнең хезмәт эшчәнлеге барышында сәламәт һәм имин хезмәт шартлары тудыру | | | | |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2025 - 2027 еллар | | | | |
| Елларга бүлеп Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны гамәлгә ашыру еллары, мең сум. | | | |
| | | 2025 | 2026 | 2027 | Гамәлгә ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 190,0 | 200,0 | 210,0 | 600,0 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | 750 | 780 | 820 | 2350 |
| | Барлыгы | 940,0 | 980 | 1030 | 2950,0 |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре, нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Чараларны гамәлгә ашыру 2027 елга хезмәтне саклау таләпләрен бозулар санын киметергә һәм производствода бәхетсезлек очраклары санын киметергә мөмкинлек бирәчәк. | | | | |
| Программаның үтәлешен тикшереп торуны оештыру системасы | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты квартал саен һәм һәр ел йомгаклары буенча Программаның гамәлгә ашырылуын тикшереп тора. Килеп туган социаль-икътисадый вәзгыятьне исәпкә алып, Программа чараларын төгәлләштерү буенча билгеләнгән | | | | |

| | |
|---|---|
| | тәртиптә тәкъдимнәр кертә |

**2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программалы ысуллар белән хәл итү кирәклеген нигезләү**

Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге дәрәҗәсендә программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру зарурлыгын билгели торган мөһим фактор булып әлеге проблеманың районның хезмәткә сәләтле халкының тормыш сыйфатын күтәрү һәм сәламәтлеген саклау өлешендә социаль әһәмияте тора.

Эшләүче халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлү очракларын киметү эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып эшләүче халыкның хезмәт шартларын һәм хезмәтен саклауны яхшырту, һөнәри куркынычны профилактикалау һәм киметү буенча чаралар күрү, шулай ук эшләүчеләргә диспансеризация һәм профилактик тикшерү уздыру тора.

**3 бүлек. Программаның максатлары һәм бурычлары**

Программаның Максатлары:

- район оешмаларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту.

Программаның Бурычлары:

- производствода травматизм дәрәҗәсен киметү, беренче чиратта авыр һәм үлем белән тәмамланган;
- хезмәткәрләрнең хезмәт эшчәнлеге барышында сәламәт һәм имин хезмәт шартлары тудыру.

**4 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары**

Программаны гамәлгә ашыруның арадаш һәм ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү өчен түбәндәге нәтиҗәлелекне бәяләү индикаторлары кулланылачак:

| № | Индикатор исеме | Санау методикасы | Чыганаклар |
|---|---|---|---|

| т/б | | | |
|---|---|---|---|
| | Бәхетсезлек очраклары саны, бер. | № - саны | Дәүләт хезмәт инспекциясе |

**5 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау**

| № т/б | Программа чараларының исеме | Программа чараларын башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлекләре | Шул исәптән сроклар буенча (мең сум) | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | | Барлыгы 2025-2027 елларны финанслау |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | |
| Максат: район оешмаларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту | | | | | | | | | | | |
| | Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары | | | Бәхетсезлек очраклары саны,берәмлек | 2 | 0 | 1 | | | | |
| 1 нче бурыч. Производствода травматизм дәрәҗәсен киметү, беренче чиратта авыр һәм үлем белән тәмамланган | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Хезмәтне саклау буенча Координация советларын үткәрү | Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге | 2025 - 2027 еллар | Уздырылган утырышлар саны, берәмлек | 12 | 12 | 12 | финанслау таләп ителми | |
| | Хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышы турында кварталлык доклад әзерләү һәм җитештерүдәге имгәнүләрне анализлау | Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге | 2025 - 2027 еллар | Докладлар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | |
| | Районның мәгариф оешмаларында хезмәтне саклау һәм янгын куркынычсызлыгы торышын тикшерү | Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге | 2025 - 2027 еллар | Үткәрелгән тикшерүләр саны, берәмлек | 10 | 10 | 10 | финанслау таләп ителми | |
| | Ведомство буйсынуындагы физик культура һәм спорт учреждениеләрендә хезмәтне саклау һәм янгын | Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге | 2025 - 2027 еллар | Үткәрелгән тикшерүләр саны, берәмлек | 10 | 10 | 10 | финанслау таләп ителми | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | куркынычсызлыгы торышын тикшерү | | | | | | | | | | |
| 2 нче бурыч. Хезмәткәрләрнең хезмәт эшчәнлеге процессында сәламәт һәм имин хезмәт шартлары тудыру | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | | |
| | Район оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларын иң яхшы оештыруга район смотр-конкурсын үткәрү | Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге | 2025 - 2027 еллар | Конкурста катнашкан предприятиеләр саны, берәмлек | 5 | 6 | 7 | | | | |
| | Хезмәтне саклау буенча буклетлар, плакатлар эшләү, әзерләү һәм искәрмәләр тарату | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2025 - 2027 еллар | Әзерләнгән материаллар саны, данә | 150 | 150 | 150 | 70 | 80 | 90 | 240 |
| | Хезмәтне саклау буенча басма искәрмәләр әзерләү, соңыннан район учреждениеләрендә тарату | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2025 - 2027 еллар | Әзерләнгән материаллар саны, данә | 150 | 150 | 150 | 120 | 120 | 120 | 360 |
| | Ел саен үткәрелә торган шәһәр | Алексеевск муниципаль | 2025 - 2027 еллар | Уздырылган киңәшмәләр | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Бөтендөнья хезмәтне саклау көне» н үткәрү | районы башкарма комитеты | | саны, берәмлек | | | | | | | |
| | Оешмаларда хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышы турында район халкына мәгълүмат бирү | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, массакүләм мәгълүмат чаралары | 2025 - 2027 еллар | Бастырылган мәкаләләр саны | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | | |
| | | | | | | | | Оешма бюджеты | | | |
| | Район предприятиеләрен дә чараларны тәэмин итү | Эшмәкәрлек һәм башка эшчәнлек субъектлары | 2025 - 2027 еллар | - | - | - | - | 750 | 780 | 820 | 2350 |
| Барлыгы | | | | | | | | 940 | 980 | 1030 | 2950 |

**6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү**

2025 - 2027 елларга Программаны финанслау күләме 2950,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны гамәлгә ашыру еллары буенча 2025 елда – 940,0 мең сум, 2026 елда – 980,0 мең сум, 2027 елда – 1030,0 мең сум.

Программаны финанслау чыганагы булып Алексеевск муниципаль районы бюджеты, район оешмалары һәм предприятиеләре акчалары тора.

**Искәрмә:** финанслау күләмнәре фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып төзәтелергә тиеш.

**7 бүлек. Программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү**

Программа куелган максатларга ирешүне тәэмин итә торган оештыру, методик, санитария-гигиена, укыту-пропаганда, җитештерү һәм башка чараларның бердәм комплексы буларак формалаштырылган һәм гамәлгә ашырыла.

Программаны эшләгәндә программа чараларын гамәлгә ашырганда социаль нәтиҗәгә ирешүгә бер үк вакытта юнәлеш тотканда, аны тормышка ашыруга чыгымнарны оптимальләштерүгә аерым игътибар бирелде.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә:

1) эш бирүчеләрнең күбрәк игътибарын хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау проблемаларына җәлеп итү;

2) район оешмаларында хезмәтне саклау буенча белгечләр санын арттыру;

3) оешмаларда хезмәтне саклау белән идарә итүгә системалы характер бирү.

Хезмәт шартларын яхшыртудан һәм хезмәтне саклаудан гомумикътисадый файда күренә:

1) вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек буенча пособиеләр түләүне киметү нәтиҗәсендә оешмаларның керемнәрен, шулай ук бюджетка салым керемнәрен арттыруда;

2) травматизмга һәм авыруларга бәйле рәвештә хезмәткә сәләтен югалтуга бәйле эш вакыты югалтулар санын кыскартуда;

3) производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан алынган зыянны каплауга бәйле чыгымнарны киметүдә;

4) Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру нәтиҗәсендә алынган табыш күләмен арттыруда;

5) хезмәт шартларын яхшырту исәбенә кадрлар алмашынучанлыгын киметүдә.

Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау чараларын гамәлгә ашыручы оешмалар шулай ук гамәлдәге законнар таләпләрен бозган өчен штрафларны киметү исәбенә икътисадый файда ала.

Программаны үтәүнең социаль нәтиҗәсе производствода имгәнүләр һәм һөнәри авырулар санын киметүдә, хезмәт куркынычсызлыгын һәм хезмәткәрләрнең социаль якланганлыгын арттыруда чагылачак. Программаны гамәлгә ашыру халыкның, бигрәк тә хезмәткә сәләтле яшьтә үлүчеләр санын киметү өчен уңай алшартлар тудыра.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**